РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.07.2019 №775-п

Саба муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукыннан азат булган муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Эзмә авыл җирлеге, Өтернәс авылы, Тукай урамы, 22 нче йорт адресы буенча башлангыч гомуми белем бирү мәктәбен мәчет итеп үзгәртеп коруга бәйле рәвештә, киләчәктә җирле мөселман дини оешмасына "Дәүләт яки муниципаль милектәге дини оешмаларга дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында" 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тапшыру өчен, Саба муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү системасын камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Саба муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукыннан азат булган муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык,

шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген раслагра (теркәлә).

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 нчы елның 17 нче октябрендә кабул ителгән 1271-п нче номерлы “Саба муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукыннан азат булган муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген раслау турында”гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязов

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
09.07. 2019 ел № 475-и

**Саба муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукыннан азат булган муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеге**

| № ч/б | Мөлкәт реестрында Номер | Урнашу урыны адресы | Күчемсез милек объекты төре: күчемле милек | Кадастр номеры | Мәйдан | Исәпкә алу объектының исеме | Хокук иясе | Мөлкәткә карата чикләүләр турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | ТС 38-000808 | Татарстан Республикасы. Саба муниципаль районы. Корсабаш ав., Совет ур., 18 | Торак булмаган бина | 16:35:100101:370 | 181,2 | Авыл мәдәният йорты | Саба муниципаль районы | Юк |